ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ
ул. Карима Тинчурина, д. 29, г. Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ
К.Тинчурин ур., 29 йорт, Казан шәһәре, 420021

Телефон: (843)211-66-94, факс: (843)211-66-47, E-Mail:ojm@tatar.ru, сайт:http://ojm.tatarstan.ru

Приказ | Казан шәһәре | Боерык

07.08.2023 № 227- од

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының аерым боерыкларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча эшне камилләштерү максатларында

боерам:

1. Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының аерым боерыкларына кертелә торган үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә, дип билгеләргә.

Рәис Ф.С. Батков

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2023 елның 07 августындагы 227-од номерлы боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының аерым боерыкларына кертелә торган үзгәрешләр

1. «Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 07 июнендәге145-од номерлы боерыгында (алга таба – 2018 елның 07 июнендәге 145-од номерлы Боерык) (Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 14 ноябрендәге 344-од номерлы, 2019 елның 12 декабрендәге 392-од номерлы, 2020 елның 22 апрелендәге 125-од номерлы, 2020 елның 05 ноябрендәге 338-од номерлы, 2021 елның 02 июнендәге 161-од номерлы, 2021 елның 31 августындагы 257-од номерлы, 2021 елның 23 сентябрендәге 288-од номерлы, 2022 елның 07 апрелендәге 79-од номерлы, 2022 елның 29 сентябрендәге боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән):

преамбулада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләре белән алыштырырга;

2018 елның 07 июнендәге 145-од номерлы боерык белән расланган Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча Регламент):

2.6.1 пунктында:

2 пунктчада:

икенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

өченче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

алтынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

уналтынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

унҗиденче абзацта «1-4 пунктчаларындагы» сүзләрен «1,3 һәм 4 пунктчалардагы» сүзләре белән алыштырырга;

2.6.2 пунктында:

2 нче пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга;

2. «Капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәт бирү (шул исәптән капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәткә үзгәрешләр кертү һәм мондый рөхсәт срогын озайту белән бәйле рәвештә капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәткә үзгәрешләр кертү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 07 июнендәге 146-од номерлы Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты боерыгында (алга таба - 2018 елның 07 июнендәге 146-од номерлы Боерык) (Татарстан Республикасы

Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 14 ноябрендәге 344-од номерлы, 2019 елның 12 декабрендәге 393-од номерлы, 2020 елның 27 апрелендәге 128-од номерлы, 2020 елның 05 ноябрендәге 339-од номерлы, 2021 елның 30 апрелендәге 121-од номерлы, 2021 елның 31 августындагы 256-од номерлы, 2021 елның 27 сентябрендәге 292-од номерлы, 2022 елның 31 мартындагы 73-од номерлы, 2022 елның 05 октябрендәге 354-од номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән):

преамбулада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләре белән алыштырырга;

2018 елның 07 июнендәге 146-од Боерыгы белән расланган Капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәт бирү (шул исәптән капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәткә үзгәрешләр кертү һәм мондый рөхсәт срогын озайту белән бәйле рәвештә капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәткә үзгәрешләр кертү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Төзелешкә рөхсәт бирү регламенты):

2.6.1 пунктында:

2 пунктчада:

унҗиденче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

унсигезенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга.

2.6.1 пунктның 3 нче пунктчасындагы өченче абзацта «дәүләт хакимияте башкарма органы» дигән сүзләрне «республика башкарма хакимияте органы» дигән сүзләр белән алыштырырга;

3. «Индивидуаль торак төзелеше яки бакча йорты объектының планлаштырылган төзелеше турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларның билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруның рөхсәт ителүе турында хәбәрнамә җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 11 ноябрендәге 345-од номерлы боерыгында (Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2021 елның 4 июнендәге 163-од номерлы, 2021 елның 31 августындагы 255-од номерлы, 2021 елның 28 сентябрендәге 293-од номерлы, 2022 елның 12 апрелендәге 84-од номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән):

преамбуладагы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы» сүзләрен «республика башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарлары үз көчен югалткан дип тану турында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы» сүзләренә алмаштырырга.

4. «Төзелгән яки реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше яки бакча йорты объектларының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында Россия Федерациясе

законнары таләпләренә туры килүе турында хәбәрнамә җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 11 ноябрендәге 346-од номерлы боерыгында (Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2021 елның 4 июнендәге 164-од номерлы, 2021 елның 31 августындагы 258-од номерлы, 2021 елның 27 сентябрендәге 291-од номерлы, 2022 елның 08 апрелендәге 81-од номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән):

преамбулада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләре белән алыштырырга.